**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592)
7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс
(885592) 7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_19__» ___11____ 2024 ел.** **№__240__**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү хакында

Азнакай муниципаль районы 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Азнакай муниципаль районының муниципаль берәмлеге бюджеты карар проекты буенча гавами тыңлауларны уздыру юлы фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы», Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында"гы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында"гы Нигезләмә нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карар проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрүне билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрү инициаторы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты - 2024 елның 6 декабрендә 17.30 сәгатьтә;

- үткәрү урыны - Азнакай шәһәре, Ленин ур., 22 йорт, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының кече залы;

- фикер алышу мәсьәләсе буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә:  Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 22 йорт, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы.

4. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына Азнакай муниципаль районы норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән вакытларда  Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының “2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Азнакай муниципаль районы бюджеты турында"гы карар проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга.

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карар проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү буенча оештыру комитеты (эшче төркем) составын кушымта нигезендә расларга.

6. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карар проектын Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru урнаштырырга.

7.  Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru.һәм «Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы»нда бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанс буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Башлык М.З.Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
Башлыгы карарына кушымта
«_____» ___________ 2024 №______

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026-2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карар проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү буенча оештыру комитеты (эшче төркем) составы**

*Оештыру комитеты рәисе (эшче төркем):*

| | |
|---|---|
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

*Оештыру комитеты секретаре (эшче төркем):*

| | |
|---|---|
| Серегина О.Б. | «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнең фаразлау һәм икътисадый анализ бүлеге баш белгече |

*Оештыру комитеты әгъзалары (эшче төркем):*

| | |
|---|---|
| Гурьянова Л.К. | «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы» МКУ рәисе |
| Габитова З.С. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |
| Галиева Ф.Г. | Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы депутаты, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башлыгы |
| Рәшитова М.М. | Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |